ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.05.2015 Казан ш. № 10-10/кс

***2015 – 2018 елларга «Торак-коммуналь хужалык (Инженерлык челтәрләре)» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар билгеләү турында***

«Коммуналь комплекс оешмаларының тарифларын җайга салу нигезләре турында» 2004 елның 30 декабрендәге 210-ФЗ санлы Федераль законга, «Коммуналь комплекс оешмалары эшчәнлеге өлкәсендә бәя кую нигезләре һәм тарифларны, өстәлмәләрне һәм чик индексларны җайга салу тәртибе турында» 2008 елның 14 июлендәге 520 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, Россия Федерациясе Региональ үсеш министрлыгының «Коммуналь комплекс оешмалары эшчәнлеге өлкәсендә тарифларны һәм өстәлмәләрне исәпләп чыгару буенча Методик күрсәтмәләрне раслау турында» 2011елның 15 февралендәге 47 санлы боерыгына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 санлы карары белән расланган Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Торак-коммуналь хужалык (Инженерлык челтәрләре)» муниципаль унитар предприятиесе тарафыннан каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны, календарь чорларына бүлеп, әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2015 елның 1 августыннан 2018 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү өлкәсендә әлеге карарның 2 нче пунктында күрсәтелгән тарифларның гамәлдә булу чорына «Торак-коммуналь хужалык (Инженерлык челтәрләре)» муниципаль унитар предприятиесе җитештерү программасының төп күрсәткечләрен әлеге карарның 2 кушымтасына нигезләнеп килештерергә.

4. «Торак-коммуналь хужалык (Инженерлык челтәрләре)» муниципаль унитар предприятиесенә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 30 декабрендәге 1140 санлы карары белән расланган мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә билгеләнгән вакытка халыкка җиткерелергә тиешле мәгълүматны ачарга.

5. Әлеге карарда билгеләнгән каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитетының «Коммуналь комплекс оешмалары хезмәт күрсәтүләреннән файдаланучыларның файдалану мөмкинлеген билгеләү өчен кулланыла торган критерийлар системасын урнаштыру турында» 2015 елның 24 февралендәге 44 санлы боерыгы белән расланган коммуналь комплекс оешмалары товарларыннан һәм хезмәт күрсәтүләреннән файдаланучыларның файдалану мөмкинлеген билгеләү өчен кулланыла торган критерийларына туры килә.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән соң ун көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты рәисе вазифаларын башкаручы А.Л. Штром

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты карарына
1 нче кушымта
29.05.2015 № 10-10/кс

2015 – 2018 елларга, календарь чорларына бүлеп,
«Торак-коммуналь хужалык (Инженерлык челтәрләре)» муниципаль унитар предприятиесе
тарафыннан каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү буенча
күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар

| № п/п | Коммуналь комплекс оешмасы, муниципаль берәмлек атамасы | Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү буенча күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар, сум/куб.м | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2015 елның 1 августыннан 2015 елның 31 декабренә кадәр | 2016 елның 1 гыйнварыннан 2016 елның 30 июненә кадәр | 2016 елның 1 июленнән 2016 елның 31 декабренә кадәр | 2017 елның 1 гыйнварыннан 2017 елның 30 июненә кадәр | 2017 елның 1 июленнән 2017 елның 31 декабренә кадәр | 2018 елның 1 гыйнварыннан 2018 елның 30 июненә кадәр | 2018 елның 1 июленнән 2018 елның 31 декабренә кадәр |
| | Әлмәт муниципаль районы | | | | | | | |
| 1 | «Торак-коммуналь хужалык (Инженерлык челтәрләре)» МУПы* | 86,16 | 86,16 | 86,95 | 86,95 | 89,12 | 89,12 | 89,78 |

<*> салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дүләт комитеты тариф турында карарлар кабул итүне
оештыру, тикшерүдә тоту һәм тәэмин итү бүлеге

Татарстан Республикасы тарифлар
буенча Дәүләт комитеты карарына
2 нче кушымта
29.05.2015 № 10-10/кс

# Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү өлкәсендә «Торак-коммуналь хужалык (Инженерлык челтәрләре)» муниципаль унитар предприятиесе җитештерү программасының төп күрсәткечләре

| № п/п | Коммуналь комплекс оешмасы атамасы | 2015 елның 1 августыннан 2015 елның 31 декабренә кадәр | | | | | 2016 елның 1 гыйнварыннан 2016 елның 31 декабренә кадәр | | | | | 2017 елның 1 гыйнварыннан 2017 елның 31 декабренә кадәр | | | | | 2018 елның 1 гыйнварыннан 2018 елның 31 декабренә кадәр | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Коммуналь комплекс оешмасы җитештерү программасы күрсәткечләре | | | | Кирәкле тулаем керем, мең сумда (НДС-тан тыш) | Коммуналь комплекс оешмасы җитештерү программасы күрсәткечләре | | | | Кирәкле тулаем керем, мең сумда (НДС-тан тыш) | Коммуналь комплекс оешмасы җитештерү программасы күрсәткечләре | | | | Кирәкле тулаем керем, мең сумда (НДС-тан тыш) | Коммуналь комплекс оешмасы җитештерү программасы күрсәткечләре | | | | Кирәкле тулаем керем, мең сумда (НДС-тан тыш) |
| | | Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү күләме, шул исәптән, мең куб.м: | | | | | Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү күләме, шул исәптән, мең куб.м: | | | | | Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү күләме, шул исәптән, мең куб.м: | | | | | Каты көнкүреш калдыкларын утильләштерү һәм күмү күләме, шул исәптән, мең куб.м: | | | | |
| | | Барлыгы | Халык | Бюджет кулланучылары | Башка кулланучылар | | Барлыгы | Халык | Бюджет кулланучылары | Башка кулланучылар | | Барлыгы | Халык | Бюджет кулланучылары | Башка кулланучылар | | Барлыгы | Халык | Бюджет кулланучылары | Башка кулланучылар | |
| 1 | «Торак-коммуналь хужалык (Инженерлык челтәрләре)» МУПы* | 8,413 | 4,8 | 2,064 | 1,549 | 724,89 | 8,413 | 4,8 | 2,064 | 1,549 | 728,21 | 8,413 | 4,8 | 2,064 | 1,549 | 740,63 | 8,413 | 4,8 | 2,064 | 1,549 | 752,53 |

<*> салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дүләт комитеты тариф турында карарлар кабул итүне
оештыру, тикшерүдә тоту һәм тәэмин итү бүлеге